БӨТЕНДӨНЬЯ ТАТАР КОНГРЕССЫ
ВСЕМИРНЫЙ КОНГРЕСС ТАТАР
WORLD CONGRESS OF THE TATARS

420060, Казань-60, Всемирный конгресс татар,
тел.: (843) 236 59 16, факс: (843) 264 63 37
www.tatar-congress.org

420060, Казан шәһәре,
Бөтендөнья татар конгрессы
тел.: (843) 236 59 16, факс: (843) 264 63 37
E-mail: tatar-congress@mail.ru

Исх. № 21-982 от «21» 09.2021

на №

Бөтендөнья татар конгрессының
Татарстан Республикасында
һәм Россия Федерациясе
регионнарында җирле
иҗтимагый оешмасы
җитәкчеләренә

Бөтенроссия “Каз өмәсе” фестивале турында

**Хөрмәтле җирле иҗтимагый оешма җитәкчеләре!**

Милләтебезнең рухи һәм мәдәни кыйммәтләрен саклау һәм үстерү, календарь бәйрәмнәрне халкыбызга кайтару, шәхси хуҗалыкларда традицион булган кош-корт үрчетүне тергезү максатыннан, Бөтендөнья татар конгрессы “Каз өмәсе” фестивале үткәрә. Фестивальгә әзерлек йөзеннән, 7 номинациядә бәйгеләр оештырыла. Шул бәйгедә җиңүчеләр кыйммәтле бүләкләр белән бүләкләнә һәм “Каз өмәсе” фестиваленә чакырыла. Фестивальне үткәрү тәртибе һәм бәйге номинацияләре белән танышу өчен әлеге хатка нигезләмә (3 б.) теркәлә (*Кушымта №1*).

Олы ихтирам белән

Татарстан Республикасы
Премьер-министры урынбасары,
Бөтендөнья татар конгрессының
Милли Шура рәисе

В.Г. Шәйхразыев

Башкаручы: К.Р. Идрисова
тел.: +7 (987) 291-24-28

**БӨТЕНРОССИЯ**
**«КАЗ ӨМӘСЕ» ФЕСТИВАЛЕНЕҢ**
**НИГЕЗЛӘМӘСЕ**

## 1. ГОМУМИ НИГЕЗЛӘМӘ

1.1. Әлеге нигезләмә Бөтенроссия «Каз өмәсе» фестиваленең (алга таба – **Фестиваль**) максатларын һәм бурычларын, оештыру тәртибен һәм шартларын билгели.

1.2. Фестиваль 2 өлештән тора: 1. Милли рух һәм мәдәни кыйммәтләрне саклау, үстерү (ТР _____________, ноябрь);
2. Социаль-экономик үсешне тәэмин итүдә ярминкә-фестивальләр (ТР Яр Чаллы шәһәре, декабрь).

## 2. ФЕСТИВАЛЬНЕҢ МАКСАТЛАРЫ ҺӘМ БУРЫЧЛАРЫ

- Милләтебезнең рухи, мәдәни кыйммәтләрен саклау һәм үстерү;
- Календарь бәйрәмнәрне халкыбызга кире кайтару;
- Шәхси хуҗалыкларда, йолаларга таянып, традицион булган кош-корт үрчетүне тергезү;
- Милли кухняны пропагандалау йөзеннән мастер-класслар оештыру;
- Милләтебезне берләштерү йөзеннән халкыбызда сакланган «өмәләр традициясен» саклау һәм җәелдерү;
- Технологияләр нигезендә каз-үрдәк продукциясен эшкәртү һәм яңа дизайн форматта халыкка тәкъдим итү;
- Кош-корт продукциясен популярлаштыру максатыннан ярминкәләр уздыру.

## 3. ФЕСТИВАЛЬНЕ ОЕШТЫРУ КОМИТЕТЫ

3.1. Фестивальне оештыручылар:

- «Бөтендөнья татар конгрессы» Регионара иҗтимагый оешмасы;
- Татарстан Республикасының ___________ муниципаль районы;
- Бөтендөнья татар эшмәкәрләренә ярдәм итү ассоциациясе;
- «Ак калфак» Региональ татар хатын-кызларының иҗтимагый оешмасы;
- «Россиянең татар авыллары» Бөтенроссия иҗтимагый оешмасы;
- Татар халык ашлары координацион Советы;
- «Татар гаиләсе» Бөтенроссия иҗтимагый фонды;
- Этно-, агро-, экотуризм өлкәсендә эш алып баручы тур операторлар («Идел-Урал» – Оренбург өлкәсе, «Хәзинә» – Башкортостан Республикасы);
- Бөтентатар төбәк тарихын өйрәнүчеләр җәмгыяте.

3.2. **Оештыру комитеты** Фестивальнең **Жюри** составын раслый.

## 4. ФЕСТИВАЛЬНЕ ҮТКӘРҮ ТӘРТИБЕ

4.1. **Фестивальдә** катнашу бушлай.

4.2. Фестиваль 7 номинациядә үткәрелә:

1. Каз өмәләренә багышланган видеоматериаллар, шигырь һәм җырлар, бию һәм сәхнәләштерелгән композицияләр (видео форматта җибәрү сорала);
2. Каз-үрдәктән пешерелгән татар халык ашлары (видео форматта ничек пешерелүен һәм төгәл рецептларын җибәрү сорала);
3. Каз-үрдәк мамыгыннан ястык-мендәрләр тутыру һәм матур итеп чигелеш белән тәэмин итү (фотосурәтләр һәм видео форматта җибәрү сорала);
4. Каз-үрдәк каурый һәм канатларыннан эшләнелгән халык кәсепләре эшләнмәләре (фотосурәтләр һәм видео форматта җибәрү сорала);
5. Каз һәм үрдәк продукцияләрен яңа дизайн форматта халыкка тәкъдим итү ысуллары (дизайнерлар бәйгесе) һәм "Үз-үземә режиссер" видеоформат конкурсы;
6. Яңа технологияләр нигезендә эшкәртелгән каз-үрдәк продукциясе конкурсы;
7. Күпләп каз-үрдәк асраучы гаилә һәм фермерларның туй казларын, тере ата һәм ана казларны милли киемгә киендерү бәйгесе.

4.3. **Фестивальдә** катнашырга теләк белдерүчеләр тиешле үрнәктәге анкетаны (*Кушымта №2*), фото- һәм видеоматериалларны һ.б. 2021 елның 20 октябрьдан да соңга калмыйча **ak.kalfak@mail.ru** электрон адресына җибәрергә тиеш.

4.4. **Жюри** әгъзаларының карары Беркетмә белән рәсмиләштерелә һәм соңгы документ булып кала, ул яңадан каралмый һәм аңа карата шикаять бирелми.

## 5. НӘТИҖӘЛӘР ЧЫГАРУ ҺӘМ БҮЛӘКЛӘҮ

5.1. **Жюри** карары нигезендә **Фестиваль** җиңүчеләренә Гран-при, I, II, III урыннар билгеләнә.

5.2. Гран-при, I, II, III урын яулаган **Фестиваль** җиңүчеләре кыйммәтле бүләкләр һәм дипломнар белән бүләкләнә.

*Кушымта №2*

***Заявка:***

| Исеме, фамилиясе, этисенең исеме | Туган көне, ае, елы | Яшәү урыны | Паспорт сериясе, номеры | Машина номеры | Катнашу номинациясе | Элемтә өчен телефон номеры, электрон адресы |
|---|---|---|---|---|---|---|
| | | | | | | |